

Блокадалы Ленинград Сания Алим кызы Богданованын язмышына мәнгегә язылган.
Ана балачагында ук Нева шәһәренә фашистлар һожvме дәһшәтләрен кичерергә туры килә. Ул чорнын авырлыгын кvз яшьләрсез генә житкерv очен кайчагында сvзләр житми. Биш яшьлек Алим кызы Санияне Ленинградтан туган Краснослободск якларына момкинлек тугач ук алып киләләр. Бу шәһәрдә бетмәс-токәнмәс бомбалар, снарядлар шартлаулары, сугыш сиреналары озелv, шулай ук жимерелv, ачлык, салкында туныпяшәvләре баланын куркулы хатирәләрендә озак еллар vткәннәр тавышы булып саклана.
Сания Алим кызы Богданова «Блокадалы Ленинградта яшәvче» («Житель блокадного Ленинграда») статусына һәм билгесенә ия. Россиянен Хәрби дан һәм Ленинградны фашистлар блокадасыннан тулысынча азат итv конендә, «Блокадалы икмәк» Ботенроссия акциясен уздыру конендә аны, якташы Зинаида Петровна Федосеева белән бергә, Краснослободск районы ветераннар советы рәисе А.Н.Шпагин, ГКУ «Соцзащита населения по Краснослободскому району РМ» директоры Т.И.Горбылева һәм «Поиск» кvппрофильле лицеенын эзтабарлар отряды гвардеецы Артем Мулланов каршы алды. Азык-толек жыелмасы тутырылган пакетларны тапшырып, рәхмәт сvзләрен әйттеләр; иминлек һәм сәламәтлек теләделәр. Бу очрашу блокадалы Ленинградта яшәvчеләргә рәхмәт кенә тvгел, дәһшәтле фашистларны жингән совет солдатларынын батырлыгы турында хәтер чагылышы да булды.